*«Ата-анагызны, якын кардәшләрегезне ничек сөйсәгез, милләтегезне дә шулай сөегез. Милләтегезгә хезмәт итүне җаныгызга бәхет дип белегез…»*

*Р. Фәхреддин*


МӘГЪНӘСЕ
СОРАУЛАРЫ
ЯСАЛЫШЫ
ИСЕМ
ҖӨМЛӘДӘГЕ ФУНКЦИЯСЕ
ТЕСТЛАР
МӘКАЛЬЛӘР
АУДИО БИРЕМНӘР

# *МӘГЪНӘСЕ*

**Предметны яки затны белдерә**

# СОРАУЛАРЫ

- КЕМ?
- НӘРСӘ?

# ИСЕМНӘРНЕҢ ЯСАЛЫШЫ

- ТАМЫР
- ЯСАЛМА
- КУШМА
- ТЕЗМӘ
- ПАРЛЫ
- КЫСКАРТЫЛМА

# Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр

- Ялгызлык исемнәр төрдәш предметларның һәм затларның берсенә генә бирелә, баш хәрефтән языла.
- Уртаклык исемнәр – төрдәш предметларның барысы өчен дә уртак атамалар.

# ИСЕМНӘРНЕҢ ҖӨМЛӘДӘГЕ ФУНКЦИЯСЕ

- Баш килештәге исем җөмләдә ия, хәбәр, тәмамлык, аергыч, хәл һәм эндәш сүз булып килергә мөмкин.
- Иялек килешендәге исем җөмләдә аергыч һәм тәмамлык булып килә.
- Юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешендәге исемнәр җөмләдә тәмамлык, хәл булып киләләр.
- Төшем килешендәге исем бары тик тәмамлык булып килә.

# Әниемә рәхмәт, әтиемә рәхмәт

Дисбе кебек тезеп,
Иң кадерле сүзем
Күңел түрләренә төрелгән.
Әниемә рәхмәт,
Әтиемә рәхмәт,
Әйтәлмичә озак йөрелгән.
Авыр тормыш итү,
Кеше булып җитү,
Фатихалар сездән алганчы.
Әниемә рәхмәт,
Әтиемә рәхмәт –
Кабатлармын телем талганчы.

Дисбе – четки; фатыйха – благословение, фатыйха алырга – получить благословение

# Мәкальләр

- Ата-ананы тыңлаган адәм булган, тыңламаган әрәм булган.
- Ата-бабасын искә алмаган кеше игелек күрмәс.
- Агач беленә җимешенннән, адәм – кыланмышыннан.
- Тату туганнар таштан койма корганнар.
- Туган бар җирдә ярдәм бар.

# Исемең матур, кемнәр куйган?

Тел, сүз, исем-фамилия - милләтнең йөзе, тылсымлы могҗизасы һәм сакчысы.

Һәркемгә үз исеме – күңеленә иң якын, иң кадерле исем-сүз.

**Гомәр Саттар-Мулилле**